**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Иске Ибрай авыл җирлеге башкарма комитеты**

# КАРАР

**№ 5** **23 октябрь 2017 ел**

"Иске Ибрай авыл җирлегендә 2017 елда биш һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сатып алынган савым аппаратлары өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында "Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 17 мартындагы 1 номерлы карары үз көчен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге башкарма комитетының муниципаль хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге башкарма комитеты карар:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге башкарма комитетының "Иске Ибрай авыл җирлегендә 2017 елда биш һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сатып алынган савым аппаратлары өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында "2017 елның 17 мартындагы 1 номерлы карары үз көчен югалткан дип танылсын.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш һәм ул рәсми рәвештә басылып чыккач (халыкка игълан ителгәч) үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Ибрай авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: М.Т. Миңнегулов